| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ<br>АГРЫЗСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ӘГЕРҖЕ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

30.04.2015 Әгерҗе ш. № 41-1

Әгерҗе муниципаль районында конфессияара һәм милләтара мөнәсәбәтләрнең торышы, милләтара конфликтларны иртә кисәтү һәм җәмәгать куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча бурычлар турында

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында конфессияара һәм милләтара мөнәсәбәтләрнең торышы, милләтара низагларны иртә кисәтү һәм җәмәгать куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча бурычлар, дәүләт милли сәясәтен тормышка ашыру, милләтара татулыкны һәм конфессияара татулыкны саклау, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы территориясендә җәмәгать куркынычсызлыгын тәэмин итү максатларындагы чыгышларны тыңлап һәм фикер алышканнан соң, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1.Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләрнең торышы һәм җәмәгать куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча бурычлар турындагы мәгълүматны игътибарга алырга.

2. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы башкарма комитетына (А. С. Авдеев):

– «2015-2017 елларга Әгерҗе муниципаль районында дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру» муниципаль программасында каралган чараларның үтәлешен тәэмин итәргә;

- районда яшәүчеләр арасында милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләр өлкәсендәге мәсьәләләр буенча социологик сораштыру үткәрүне оештырырга.

3.Тәкъдим итәргә:

3.1.Әгерҗе муниципаль районы авыл җирлекләре башлыкларына:

- халык арасында уяулыкны һәм оешканлыкны, гадәттән тыш хәлләрдәге гамәлләргә әзерлекне арттыруга, мәгълүмат алмашу өлешендә хокук саклау органнары белән хезмәттәшлекне ныгытуга юнәлдерелгән аңлату эшләрен оештырырга;

- теркәлмәгән затларның законсыз яшәү мөмкинлеген ачыклау максатыннан, җирлек территориясендә буш булган йортларны йөреп чыгуны оештырырга.

3.2. Әгерҗе муниципаль районы оешмалары, предприятиеләре, учреждениеләре җитәкчеләренә аеруча мөһим булган объектларның сакланышын көчәйтү буенча өстәмә чаралар күрергә;

3.3. Массакүләм мәгълүмат чараларына милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләрне гармонияләштерүгә юнәлдерелгән мәгълүмати сәясәт үткәрергә.

4.Әлеге карарны «Әгерҗе хәбәрләре» район газетасында бастырып чыгарырга һәм районның agryz.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштырырга.

5.Әлеге карарның үтәлешен үз өстемә алам.

Совет Рәисе,
Муниципаль район Башлыгы В.В.МАКАРОВ